Структурное подразделение Муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения
«Татарско-Ямалинская основная общеобразовательная школа»
Актанышского муниципального района РТ-
ОУ «Буляковская начальная школа»

| Обсуждено<br>Руководитель ШМО МБОУ<br>«Татарско-Ямалинская ООШ» АМР РТ<br>__________ /Варина Т.Р./<br>Проткол №_1_<br>от «_21_»_августа_2018 г. | Согласовано<br>Заместитель директора по УВР<br>МБОУ «Татарско-Ямалинская ООШ» АМР РТ<br>__________ /Шаймухаметова Р.Р./<br>«_23_» _август_2018 г. | Утверждаю<br>Директор МБОУ «Татарско-Ямалинская ООШ» АМР РТ<br>__________ /Файрушина Г. Г./<br>Приказ №_90-ОД_<br>От «_28_» _августа_ 2018 г. |
|---|---|---|

Рабочая программа по предмету **«Литературное чтение на родном языке», 2 класс**
Составитель: Нуриева Разима Абударовна,
учитель начальных классов первой квалификационной категории

Рассмотрено на заседании
педагогического совета.
Протокол №_1_
от «_28_» _августа_ 2018 г.

2018-2019 учебный год

**Предмет буенча планлаштырылган нәтиҗәләр**

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек | Предмет нәтиҗәсе | | Метапредмет нәтиҗәсе | Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| | Укучы өйрәнәчәк | Укучы өйрәнү мөмкинчелеген алачак | | |
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре** | -сүзләрне укыганда төгәл,дөрес әйтеп укырга, уку тизлеген арттыра барырга;<br>- текст белән беренчел танышканда эчтән укырга, терәк сүзләрне эзләп табып, кирәкле өзек белән танышырга;<br>- үз фикерен белдерү өчен, кыска монологлар төзергә, укытучы сорауларына тулы җавап бирергә;<br>укытучыны,сыйныфташла рын тыңларга, сорауларга җавап биргәндә иптәшләрен кабатламаска, үз фикерен төгәл әйтә белергә;<br>-2-3 татар, 1-2 рус классик язучысының исемен әйтергә;<br>- дәреслектә танышкан 2-3 хәзерге заман язучысы яки шагыйрен, алар язган | -укытучы укыган текстны аңлап, үз фикерен белдерергә;<br><br>-“Серле ачкыч” мәктәбе клубына хат язарга;<br><br>-укыган әсәргә үз фикерен белдерергә;<br><br>-төрле авторның 6-8 шигырен яттан укый алырга;<br><br>-китапханәдән китаплар сайлаганда, кирәкле әсәрне “Эчтәлек” битеннән эзли белергә;<br><br>-теманы өйрәнгәндә охшаш текстларны, бер үк автор әсәрләрен дәреслекнең икенче кисәгеннән эзләп таба алырга;<br><br>-укылган тексттан өземтәләр китереп. Сорауларга җавап | Регулятив күнекмәләр.<br><br>-теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, аның чишелеш юлларын билгели, аерып алынган проблеманы мөстәкыйль хәл итә, рефлексия ясый, үз эшенә адекват бәя бирә: булган белем нәтиҗәсен анализлый;<br><br>-мөстәкыйль рәвештә максатка ирешү юлларын, шулай ук альтернатив юлларын планлаштыра белү: проблеманы чишү планын төзү (проект өстендә эш); уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишкәндә туган потенциаль авырлыкларны билгеләү, аларны бетерү чараларын табу; уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишүнең шартларын, шулай ук бирелгән вариантлардан таба, билгели белү.<br><br>-үзеңнең чынбарлыкны үзгәртүгә юнәлтелгән адымыңны планлаштырылган нәтиҗәләр белән | үзеңне милләтеңнең вәкиле итеп тану;<br><br>- мотивация нигезендә белем алу һәм танып белүнең укучыларның үзлегеннән үсеш, үзлегеннән укып белем алуга әзерлек;<br><br>-шәхси сайлау нигезендә мораль (әхлакый) проблемаларны чишүдә компетентлык, үз гамәлләреңә аңлы һәм җаваплы караш формалаштыру;<br><br>-укуга җаваплы караш формалаштыру;<br><br>-башка кешегә, аның уй-фикеренә хөрмәтле һәм игелекле караш булдыру;<br><br>-бердәм башкарыла торган |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | әсәрне әйтергә,эчтәлеген сөйләргә;<br>- үзенең яраткан авторы турында, аның әсәрләре турында сөйли белергә;<br>-бирелгән текстның темасын, төп мәгънәсен ачыкларга (укытучы ярдәме белән);<br>-аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен “Аңлатмалы сүзлектән” карарга;<br>-әсәр геройларына характеристика бирергә.<br>-тылсымлы әкиятләрне хайваннар турындагы әкиятләрдән аерырга;<br>- тылсымлы әкиятләрнең үзенчәлеген ачыкларга; | бирергә. | тиңләштерә белү, нәтиҗәгә ирешү процессында үз эшчәнлегеңә контроль ясый белү;<br><br>-уку мәсьәләләренең дөреслегенә, аны чишкәндәге үз мөмкинлекләреңә бәя бирә белү. 5. Үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя, карар кабул итүне аңлы рәвештә сайлый белү, мөстәкыйль рәвештә уңышыңның яки уңышсызлыгыңның сәбәпләрен ачыклый белү, уңышсызлык ситуацияләреннән чыгу юлларын таба белү.<br><br>Танып-белү күнекмәләре.<br><br>-төшенчәләрне билгели, йомгаклый, аналогияләрне таба, логик фикерләү, дөрес нәтиҗә һәм йомгак ясау күнекмәләре, мөһим һәм аннан бәйле сүзләрдән торган логик чылбыр төзү; ике яки берничә предметның, күренешнең гомуми билгесен табу, аларның охшашлыгын аңлату; аерым билгеләре буенча предмет һәм күренешләрне берләштерү, чагыштыру, классификацияләү, факт һәм күренешләрне гомумиләштерү; фикер йөртүне предметларны һәм күренешләрне чагыштыру һәм гомуми билгеләрне аерып алу нигезендә төзү; алынган мәгълүматны, чишеләсе мәсьәләне | эшчәнлеккә уңай караш тудыру;<br><br>-башка шәхескә хөрмәт тудыру;<br><br>-үзеңдә лидерлык сыйфатларын тормышка ашыру ысулларын формалаштыру. |
| **Автор әсәрләре**<br><br>**Әдәби жанрлар** | -әкият һәм хикәяне аерырга;<br>-әсәрдә сурәтләү чараларын табарга(чагыштыру, капма-каршылык, кабатлаулар, җанландыру һ.б.); | -автор әсәрләрендә фолҗклор элементларының чагылышын, әкиятләрнең сюжет- композициясе үзенчәлекләрен ачыкларга;<br><br>-әдәби әсәрләр һәм фольклор арасындагы чикнең сыгылмалылыгын билгеләргә(хикәядә–әкият элементлары, тылсымлы әкияттә- хайваннар турындагы әкият элементлары чагылышы); | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | - табигатьне шагыйрь күзлегеннән карап танып белергә. | контекст эчендә интерпретацияләп аңлатып бирү; | |
| **Библиографик культура**<br>**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру** | -укылганның эчтәлеген аңлап, интонация белән, уку темпын сайларга, паузалар белән укырга;<br><br>-әдәби тестны, дәреслек битендәге маркировка белән дөрес итеп рольләргә бүлеп, чылбыр рәвешендә укырга;<br><br>-программада каралган текстларны аңлап укырга һәм эчтәлеге сөйләргә. | -шигъри һәм проза әсәрләрен Сәнгатьле укып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә;<br>-дәреслектә бирелгән иллюстрацияләрне, “Музей йорты”ндагы картиналарны карап, әдәби текстлар белән чагыштырып, уртак һәм аермалы якларын табарга;<br>-әдәби һәм сәнгать әсәрләре турында телдән сөйләм төзергә. | -уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, символ, модель, схемаларны үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе;<br><br>-үз эшчәнлеге максатларына туры килгән, соралган информацияне тексттан табу; текст эчтәлегендә ориентлашу, текстның тулы мәгънәсен аңлау;<br><br>-экологик фикерләүне формалаштыру һәм үстерү, аны танып-белү;<br><br>-сүзлекләр, башка эзләнү схемаларын актив куллана белү сәләтен мотивлаштыруны үстерү. | |

**Программаның эчтәлеге**

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек | Эчтәлек | Сәг. саны |
|---|---|---|
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре** | Халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр.<br>Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, автор бәяләмәсе).<br>**Хайваннар турында әкиятләр.** Әкиятләр турында гомуми күзаллау.<br>Әкиятләрнең тәрбияви роле. Геройларның характеры, аларның акыл-фигыльләре, һәрвакыт ярдәмчел, киң күңелле булуларына игътибар итү, ишарә ясау. Күчмә сюжетлар.<br>**Тылсымлы әкиятләр.** Тылсымлы дөньядагы предметлар, әкияти төсләр, тылсымлы булышчылар. Тылсымлы әкият геройлары. Тылсым дөньясы, булышчылар, тылсымлы предметлар, тылсымлы саннар (3, 7, 13, 40).<br>**Тормыш-көнкүреш әкиятләре.** Тормыш-көнкүреш әкиятләренең килеп чыгышы. Әкиятләрдә проблемалар, үгет-нәсыйхәт, юмор хисе.<br>**Автор әкиятләре.** Автор һәм халык әкиятләрендә сюжет-композиция охшашлыгы, яңа мәгънәви төсмерләр бирү.<br>**Мәкальләр.** Мәкальләр – халыкның тормыш тәҗрибәсеннән тупланган акыллы сүзләр. Мәкальләрне төрле ситуацияләрдә урынлы куллана белергә күнектерү. Төрле халыкларның мәкальләре, аларның охшашлыгы. Әкият, мәсәл, хикәянең, иллюстрацияләрнең эчтәлегенә туры килә торган мәкальләрне дөрес сайлау. | 11 |
| **Автор әсәрләре** | Тылсымлы шигъри әкиятләр (Г. Тукай. «Су анасы», «Шүрәле» һ.б.), аларда халык әкиятләре белән сюжет бәйләнеше, композиция үзенчәлеге. Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмас матурлыгы. | 14 |
| **Әдәби жанрлар** | Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру; хикәя, шигырь.<br>**Хикәя.** Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Жанр үзенчәлеге: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы, әхлак кануннарына туры килүе, уйлап табучанлык. Әсәр исеменең төп мәгънә, эчтәлек белән туры килүе. Хикәя геройлары, | 17 |

| | | |
|---|---|---|
| | аларның портретлары, характеры, сөйләм һәм вакыйгалар аша чагылышы. Хикәя герое. Авторның геройга, вакыйгаларга, күренешләргә мөнәсәбәтен сиземли алу, үз фикереңне әйтә белү. Хикәяләрдә автор билгеләмәсе: герой портреты, катнашучы геройларга характеристика, пейзаж һәм интерьер сурәтләнеше, геройны чолгап алган тирәлек. Хикәя жанрының үзенчәлекле якларын күзәтү: а) хикәяләрдә вакыйгалар агышы (әсәр героеның характерын ачыклау өчен кызыклы хәлләр); ә) герой характерының катлаулылыгы; б) вакыйга һәм хәлләрнең киеренкелеге; в) әсәрнең сәнгатьле теле. Әсәрдә берничә сюжет сызыгы белән вакыйгалар бирелеше, геройларның кичерешләре, җиңүләре.<br>**Шигырь.** Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрьнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүе. Рифма белән танышу: аны сиземли, таба, куллана белергә күнектерү. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).<br>Төрле ел фасылларын чагыштырып, дөньяның күп төсле, формаларның күп төрле булуын аңларга ярдәм итү, матурлыкка тиешле хисләр белән җавап бирергә, оригиналь һәм стандарт булмаган фикерләргә кызыксыну уяту. Шигырьләрне укыганда әдәби сурәтләү чараларын (чагыштыру, җанландыру, капма-каршылык, лексик һәм композицион кабатланулар) эзләп табу. Авторларның иҗат алымнары, тормышлары турында күзаллау булдыру. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү. | |
| **Библиографик культура** | Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: эчтәлектән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп таба белү. Кече яшьтәге мәктәп баласының дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.<br>Теге яки бу язучы, шагыйрь иҗатын өйрәнгәннән соң, аның әсәрләреннән нәни җыентыклар төзү. Китапханәләрдән файдалана белү осталыгын үстерү, тәкъдим ителгән исемлек буенча китаплар сайлый белергә өйрәтү.<br>Әдәби китапларда җиңел ориентлашу. Китап ахырында бирелгән эчтәлек белән эшләү. Китапның элементлары: титул бите, аннотация, китапның рәссам-бизәүчеләре турында өйрәнүне дәвам итү. Мәгънәсе аңлашылмаган яисә авыр язылышлы сүзләрне сүзлекләрдән таба белергә өйрәтү. Язучы, шагыйрьләр турында чыгышлар ясау. Китапханәдә ориентлашу.<br>Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. Телдән һәм язма сөйләм күнегүләре. Аралашу культурасын ныгыту. Темага карата, әсәр буенча үз фикерләреңне төгәл әйтә белү. | 10 |
| **Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре** | Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү. Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру. Укуга карата таләпләрне төгәл үтәү: кычкырып укуның дөреслеге, сәнгатьлелеге, укуның | 16 |

| | | |
|---|---|---|
| **формалаштыру** | тизлеге.<br>Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләрне кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерын чагылдыру. Тавыш төсмерләре – интонация, тон, тавыш көче, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләрне бирү күнекмәләре.<br>Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Укылган әсәргә анализ ясау күнекмәләре. | |
| Барлыгы | | 68 сәг. |